**РАСПОРЯЖЕНИЕ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**БОЕРЫГЫ**

24.06.2019 № 226

**«Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы Попечительләр советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә:

Татарстан Республикасы Президентының 2005 елның 10 гыйнварындагы 2 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 23 гыйнварындагы 12 номерлы, 2007 елның 30 июлендәге 212 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге 98 номерлы, 2010 елның 13 гыйнварындагы 5 номерлы, 2010 елның 23 июнендәге 202 номерлы, 2010 елның 30 июлендәге 243 номерлы, 2010 елның 1 ноябрендәге 358 номерлы, 2010 елның 30 декабрендәге 440 номерлы, 2012 елның 2 мартындагы 121 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге 635 номерлы, 2014 елның 23 декабрендәге 721 номерлы, 2015 елның 21 мартындагы 213 номерлы, 2015 елның 24 августындагы 499 номерлы, 2017 елның 15 маендагы 292 номерлы, 2017 елның 21 августындагы 511 номерлы һәм 2018 елның 21 апрелендәге 160 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы Попечительләр советы (алга таба – Попечительләр советы) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Попечительләр советы составыннан Т.М. Абдуллинны чыгарырга;

Попечительләр советы составына Груничев Александр Станиславовичны – Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисен кертергә;

Попечительләр советы әгъзаларының вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

М.Р. Зариповның – «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт торак фонды» коммерциячел булмаган оешмасы башкарма директоры»;

А.К. Шиһабетдиновның – «ТАИФ» акционер җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча)».

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ